КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 19 март г.Казань № 148

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коррупциягә каршы бизнес» иҗтимагый процедуралар үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 26 июль, 598 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коррупциягә каршы бизнес» иҗтимагый процедуралар үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 26 июль, 598 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 12 апрель, 283 нче; 2019 ел, 25 декабрь, 1202 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «2015 – 2022 елларга» сүзләрен «2015 – 2023 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Коррупциягә каршы бизнес» иҗтимагый процедуралар үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә:

2 пунктта «2015 – 2022 елларга» сүзләрен «2015 – 2023 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пункт өстәргә:

«$3^1$. Субсидия турында мәгълүматлар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында «Бюджет» бүлегендә урнаштырыла.»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Субсидия Үзәккә, әгәр ул субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзергә планлаштырыла торган айга кадәр килә торган айның beresенә түбәндәге таләпләргә туры килсә, бирелә:

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пеняләр, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмаса;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмаса;

үзгәртеп оештыру (Үзәккә башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмаса, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәсә, Үзәкнең эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмаса;

чит ил юридик заты, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит илләр юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артмаган Россия юридик заты булып тормаса;

бу Тәртипнең 1.2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмаса.»;

6 пунктта:

җиденче абзацта татар текстында «һәм» сүзен – «, шулай ук» сүзләренә алмаштырырга, «вакытында түләнмәгән башка бурычлары» сүзләрен «акчалата йөкләмәләр буенча вакытыннан түләнәмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлары» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үзәк җитәкчесенең имзасы куелган Үзәкнең үзгәртеп оештыру (Үзәккә башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш) , бетерү процессында булмавы, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәве, Үзәкнең эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмавы, шулай ук бу Тәртипнең 3 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмавы турында белешмә кәгазен.»;

9 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үзәк тапшырган мәгълүматның дөрес булмау фактын билгеләү;»;

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Килешүдә субсидиянең күләме, аның максатчан билгеләнеше, аны күчерү тәртибе һәм вакытлары, субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе, субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисаплылык бирү тәртибе һәм сроклары, Үзәкнең өстәмә хисаплылык бирү срокларын һәм формаларын билгеләү өчен Министрлыкның хокукы, Үзәк тарафыннан хисап финанс елында файдаланылмый

калган субсидия өлешләрен кире кайтару очраклары, Министрлык хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешләрен файдалануга ихтыяҗ булу турында карар кабул иткәндә, әлеге субсидия акчасы финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып торган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеген күздә тота торган шарт, Үзәкнең һәм килешү буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) булып торучы затларның Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Үзәкнең субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә карата тикшерүләр үткәрүгә ризалыгы, килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмауга китерә торган, бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән бюджет йөкләмәләренең элек җиткерелгән лимитлары Министрлыкка бюджет акчасын алучы буларак киметелгән очракта яңа шартлар буенча ризалыкка ирешмәгәндә килешүне өзү турында шарт, югары технологияле импорт җайланмаларын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта турындагы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән башка, субсидия акчасы исәбеннән чит ил валютасы сатып алуны тыю, Үзәкнең бу Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәве турында нигезләмә карала.

12[1] пунктта «2015 – 2022 елларга» сүзләрен «2015 – 2023 елларга» сүзләренә алмаштырырга, «, шул исәптән ел саен, агымдагы финанс елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча, Үзәк иҗтимагый советының өч утырышын үткәрү» сүзләрен өстәргә;

13 пунктта «Үзәкнең Россия кредит оешмасында ачылган хисап исәбенә» сүзләрен «Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында Үзәк өчен ачылган хисап яки корреспондент счетларына» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Үзәк квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 15енә кадәр, Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасында күрсәтелгән форма буенча субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында Министрлыкка хисап кертә.»;

15 пунктта «Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы» сүзләрен «дәүләт финанс контроле органнары» сүзләренә алмаштырырга;

16 пунктта татар текстында «үткәрелгән» сүзеннән соң «шул исәптән» сүзләрен өстәргә, «Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы» сүзләрен «дәүләт финанс контроле органнары» сүзләренә алмаштырырга, «очракта,» сүзеннән соң «шулай ук субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешмәгән очракта» сүзләрен өстәргә.

әлеге Тәртипкә теркәлгән кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин